ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 14 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Сайлау кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 5, № 12 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш); 2018, № 44 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 28 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 48 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяда:

а) 3 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Бу чакта әлеге статьяның 2 өлешендә каралган тавыш бирү көненә кадәр биш ай алдан башлана һәм күрсәтелгән тавыш бирү көненнән соң бер ай узгач тәмамлана торган чорда муниципаль берәмлек башлыгын вакытыннан алда сайлаулар күрсәтелгән тавыш бирү көненнән башка көнне уздырыла алмый һәм, әлеге статьяның 4 – 7 өлешләрендә каралган нигезләмәләрне исәпкә алып, шушы көнгә билгеләнә.»;

б) $3^1$ өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Бу чакта әлеге статьяның 2 өлешендә каралган тавыш бирү көненә кадәр биш ай алдан башлана һәм күрсәтелгән тавыш бирү көненнән соң бер ай узгач тәмамлана торган чорда шундый сайлаулар күрсәтелгән тавыш бирү көненнән башка көнне уздырыла алмый һәм, әлеге статьяның 4 – 7 өлешләрендә каралган нигезләмәләрне исәпкә алып, шушы көнгә билгеләнә.»;

2) $6^1$ статьяда:

а) исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6[1] статья. **Югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл, хәрби хәл режимы кертелгәндә сайлаулар үткәрү**»;

б) түбәндәге эчтәлекле 5 – 11 өлешләр өстәргә:

«5. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә, «Хәрби хәл турында» 2002 елның 30 гыйнварындагы 1-ФКЗ номерлы Федераль конституциячел закон нигезендә хәрби хәл кертелгәндә, Татарстан Республикасы Рәисе тавыш бирү көненә кадәр иң күбе 130 көн һәм кимендә 90 көн кала Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенә Татарстан Республикасы территориясендә сайлаулар үткәрү турында тәкъдим җибәрергә хокуклы.

6. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе әлеге статьяның 5 өлешендә каралган тәкъдим кергән көннән алып биш көннән дә соңга калмыйча оборона өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру, норматив-хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органы һәм иминлек тәэмин итү өлкәсендә федераль башкарма хакимият органы белән консультацияләр үткәрә.

7. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә әлеге статьяның 6 өлешендә каралган консультацияләр нәтиҗәсе буенча һәм күрсәтелгән өлештә билгеләнгән срок дәвамында Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тиешле сайлауларны билгеләү (үткәрү) турында (шул исәптән сайлау гамәлләре срокларын кыскарту мөмкинлеге белән) яисә Татарстан Республикасы Рәисенең аларны үткәрү хакындагы тәкъдимен кире кагу турында карар кабул итә.

8. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе, әлеге статьяның 7 өлешендә һәм әлеге Кодексның 6 статьясындагы 5 өлешендә билгеләнгән срокларны истә тотып, Татарстан Республикасы территориясендә сайлауларны билгеләү (үткәрү) турында карар кабул итә, бу хакта кичекмәстән Россия Федерациясе Президентына хәбәр итә. Бу чакта сайлаулар тиешле дәрәҗәдәге комиссия тарафыннан оештырыла һәм үткәрелә.

9. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә, әлеге статьяның 6 өлешендә каралган консультацияләр нәтиҗәсе буенча Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе Татарстан Республикасы Рәисенең сайлаулар үткәрү турындагы тәкъдимен кире каккан очракта, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе бу хакта кичекмәстән Татарстан Республикасы Рәисенә хәбәр итә.

10. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон

нигезендә, әлеге статьяның 8 өлеше нигезендә сайлаулар билгеләнгәннән соң аларны оештыру һәм үткәрү Россия Федерациясе гражданнарының гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч тудырса, сайлаулар Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе карары белән кичектерелә, ул бу хакта кичекмәстән Россия Федерациясе Президентына хәбәр итә.

11. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә, сайлауларны кичектереп тору өчен нигез булган хәлләр бетерелгән очракта, сайлау кампаниясе Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе карары белән әлеге статьяның 5 – 8 өлешләрендә каралган тәртиптә яңадан башланырга мөмкин.»;

3) 10 статьяның 13 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон, әлеге Кодекс нигезләмәләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр, шулай ук аларның вазыйфаи затлары комиссияләргә вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда ярдәм күрсәтергә тиеш, аерым алганда, түләүсез нигездә кирәкле биналар (биналарны территория, округ һәм участок комиссияләренә биргәндә – биналардан файдалану чыгымнары һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү комиссияләр тарафыннан капланмый һәм түләнми), шул исәптән участок комиссияләренең сайлау документларын (күрсәтелгән документларны архивка тапшырганчы йә законда билгеләнгән саклау вакытлары узып юкка чыгарганчы) һәм технологик җиһазларын саклау өчен, бирергә, бирелә торган биналарны һәм күрсәтелгән документларны һәм җиһазларны сак белән тәэмин итәргә, шулай ук түләүсез нигездә транспорт чаралары, элемтә чаралары, техник җиһазлар бирергә тиеш.»;

4) 12 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ өлеш өстәргә:

«$1^1$. Казан шәһәре территориясендә җирле үзидарә органнарына сайлаулар әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы комиссия вәкаләтләре Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе белән килештерелгән карары нигезендә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә тапшырылырга мөмкин.»;

б) түбәндәге эчтәлекле $9^1$ өлеш өстәргә:

«$9^1$. Казан шәһәре территориясендә җирле үзидарә органнарына сайлаулар әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы комиссия вәкаләтләрен үтәгән очракта Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әлеге Кодексның 108 статьясында каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.»;

5) 16 статьяда:

а) 6 өлештә «$6^{1}$ өлеше» сүзләрен «$6^{1}$ яисә $6^{1-1}$ өлеше» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле $6^{1-1}$ өлеш өстәргә:

«$6^{1-1}$. Әлеге Кодексның 76 статьясындагы 19 өлешендә һәм (яисә) 77 статьясындагы 19 өлешендә каралган тавыш бирүне һәм (яисә) әлеге Кодексның $76^{1}$ статьясындагы 17 өлешендә каралган вакытыннан алда тавыш бирүне тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан махсус участок комиссияләре төзелергә мөмкин. Мондый комиссияләр шул исәптән шик белдерелгән һәм гаепләнүче затларны сак астында тоту урыннары хезмәткәрләре арасыннан төзелергә мөмкин, йә мондый участок комиссияләренең вәкаләтләре башка участок комиссияләренә йөкләнә ала.»;

6) 17 статьяның 9 өлешенә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Әлеге Кодексның 16 статьясындагы $6^{1-1}$ өлеше нигезендә төзелгән участок комиссиясе рәисе вазыйфага комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары арасыннан билгеләп куела һәм вазыйфадан Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары белән азат ителә.»;

7) 21 статьяның $1^{2}$ өлешендә «яисә түләүле граждан-хокук» сүзләрен төшереп калдырырга;

8) 22 статьяда:

а) 5 өлештә беренче җөмләдә «һәр участок комиссиясенә, территория комиссиясенә һәм округ комиссиясенә» сүзләреннән соң «(округ сайлау комиссиясе вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә йөкләү очрагыннан тыш)» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле 9 өлеш өстәргә:

«9. Фото һәм (яисә) видеога төшерү әлеге Кодекс нигезендә аны башкарырга хокукы булган затлар тарафыннан тавыш бирү сере бозылмаслык һәм сайлаучыларның ихтыяр күрсәтүен контрольдә тоту мөмкинлеге булмаслык итеп, шулай ук сайлаучылар исемлекләренә кертелгән һәм федераль законда билгеләнгән тәртиптә конфиденциаль мәгълүматка кертелгән мәгълүматы булган башка документлардагы персональ белешмәләрнең конфиденциальлеге сакланырлык итеп гамәлгә ашырылырга тиеш.»;

9) 27 статьяда:

а) 4 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Шик белдерелгән һәм гаепләнүче затларны сак астында тоту урыннарында әлеге Кодексның 76 статьясындагы 19 өлешендә һәм (яисә) 77 статьясындагы 19 өлешендә каралган тавыш бирүне һәм (яисә) әлеге Кодексның $76^{1}$ статьясындагы 17 өлешендә каралган вакытыннан алда тавыш бирүне үткәрү өчен сайлау комиссияләре Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан төзелергә мөмкин.»;

б) түбәндәге эчтәлекле $4^{1}$ өлеш өстәргә:

«4[1]. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына сайлаулар уздырганда Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары белән актив сайлау хокукына ия булган Татарстан Республикасыннан читтәге территорияләрдәге сайлаучылар тавыш бирү өчен сайлау участоклары төзелергә мөмкин. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әлеге өлештә каралган сайлау участокларында төзелгән участок комиссияләренең эшчәнлегенә җитәкчелек итү өчен бер йә берничә территория комиссиясе төзергә хокуклы. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә күрсәтелгән сайлау участокларын төзү, бу участокларда участок комиссияләрен төзү (бу участоклардагы участок комиссияләренең вәкаләтләрен Россия Федерациясенең башка субъектларында төзелгән участок комиссияләренә йөкләү), сайлаучылар исемлекләрен төзү, тавыш бирү йомгаклары турында беркетмәләр төзү (мондый тавыш бирү йомгаклары турындагы белешмәләрне булдыру), тавыш бирү нәтиҗәләрен эшкәртү, сайлауларның нәтиҗәләрен билгеләү үзенчәлекләре, шулай ук күрсәтелгән сайлау участокларында тавыш бирүне, шул исәптән вакытыннан алда тавыш бирүне, әзерләүнең һәм үткәрүнең башка үзенчәлекләре Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.»;

10) 29 статьяда:

а) 15[1] өлешнең икенче абзацында «таныклана» сүзеннән соң «, яисә мондый күчермә электрон рәвештә әзерләнергә мөмкин, бу очракта ул участок комиссиясе рәисенең, секретаренең электрон имзасы белән имзалана» сүзләрен өстәргә;

б) 17[1] өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

в) түбәндәге эчтәлекле 17[2] өлеш өстәргә:

«17[2]. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә, әлеге Кодексның 76 статьясындагы 19 өлешендә һәм (яисә) 77 статьясындагы 19 өлешендә каралган тавыш бирүне һәм (яисә) әлеге Кодексның 76[1] статьясындагы 17 өлешендә каралган вакытыннан алда тавыш бирүне үткәргән очракта, сайлаучылар исемлекләре Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе билгеләгән тәртиптә төзелә.»;

11) 47 статьяга түбәндәге эчтәлекле 13 өлеш өстәргә:

«13. Теркәлгән кандидат хөкем ителгән очракта, мондый кандидат хөкем ителгән көннән соң килгән көннең җирле вакыт буенча 18 сәгатеннән дә соңга калмыйча бу хөкем ителү турында үзен теркәгән сайлау комиссиясенә язмача белешмә тапшырырга тиеш. Кандидатның әлеге хөкем ителүе турында белешмәләр шулай ук әлеге Кодексның 49 статьясындагы 2 өлеше нигезендә кандидат исеменнән эш итү хокукы булган затлар тарафыннан да тапшырылырга мөмкин.»;

12) 52 статьяның 5 өлешендә «Ышанычлы затларның вәкаләтләре» сүзләреннән соң «, шул исәптән әлеге Кодексның 21 статьясындагы 1 өлешендә

күрсәтелгәннәре,» сүзләрен өстәргә, «бергә» сүзеннән соң «агитация чоры тәмамлану белән бер үк вакытта, шулай ук вакытыннан алда» сүзләрен өстәргә;

13) 73 статьяның 2 өлешендә «зал булырга» сүзләреннән соң «, шулай ук, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән таләпләрне исәпкә алып, күзәтүчеләр һәм әлеге Кодексның 21 статьясындагы $1^{2}$ өлешендә күрсәтелгән массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре өчен урыннар билгеләнергә» сүзләрен өстәргә;

14) 75 статьяда:

а) 16 өлештә «кимрәк була алмый» сүзләреннән соң «, моңа әлеге Кодексның $76^{2}$ статьясы нигезендә дистанцион рәвештә электрон тавыш бирүне үткәрү очрагы керми» сүзләрен өстәргә, түбәндәге эчтәлекле яңа өченче җөмлә өстәргә: «Бу очракта тапшырыла торган бюллетеньнәр саны, федераль законда башкасы билгеләнмәгән булса, сайлауларны оештыручы комиссия карары белән билгеләнә.»;

б) түбәндәге эчтәлекле $21^{1}$ өлеш өстәргә:

«$21^{1}$. Әлеге Кодексның 76 статьясындагы 19 өлешендә һәм (яисә) 77 статьясындагы 19 өлешендә каралган тавыш бирүне һәм (яисә) әлеге Кодексның $76^{1}$ статьясындагы 17 өлешендә каралган вакытыннан алда тавыш бирүне үткәргән очракта һәм әлеге Кодексның 27 статьясындагы $4^{1}$ өлешендә күрсәтелгән сайлау участокларында тавыш бирүне үткәргәндә сайлау документларын, бюллетеньнәрне дә кертеп, турыдан-туры участок комиссиясе тарафыннан әзерләү рөхсәт ителә, бу чакта әлеге статьяның 3 өлеше нигезләмәләре кулланылмаска мөмкин. Сайлау документларын әзерләү турында карар, бюллетеньнәрнең кирәкле булган тиражын һәм аларны әзерләү срокларын күрсәтеп, югарырак комиссия белән килештереп, участок комиссиясе тарафыннан кабул ителә.»;

15) 76 статьяда:

а) $2^{1}$ өлештә «сайлау участокларында» сүзләреннән соң «, шулай ук әлеге статьяның 19 өлешендә һәм (яисә) әлеге Кодексның 77 статьясындагы 19 өлешендә каралган тавыш бирүне һәм (яисә) әлеге Кодексның $76^{1}$ статьясындагы 17 өлешендә каралган вакытыннан алда тавыш бирүне үткәрү өчен төзелгән сайлау участокларында» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле 19 өлеш өстәргә:

«19. Тиешле сайлау округыннан читтә һәм тиешле сайлау округы чикләрендә булган шик белдерелгән һәм гаепләнүче затларны сак астында тоту урыннарындагы сайлаучыларның сайлаулар үткәргәндә тавыш бирүе, «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон таләпләрен исәпкә алып, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә аның карары белән гамәлгә ашырыла.»;

16) $76^{1}$ статьяга түбәндәге эчтәлекле 17 өлеш өстәргә:

«17. Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе карары белән, тиешле сайлау округыннан читтә һәм тиешле сайлау округы чикләрендә булган шик белдерелгән һәм гаепләнүче затларны сак астында тоту урыннарындагы сайлаучыларның сайлаулар үткәргәндә вакытыннан алда тавыш бирүе, «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон таләпләрен исәпкә алып, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда гамәлгә ашырыла.»;

17) 77 статьяда:

а) 2 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Күрсәтелгән реестр «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе билгеләгән тәртиптә электрон рәвештә төзелергә мөмкин.»;

б) түбәндәге эчтәлекле 19 өлеш өстәргә:

«19. Тиешле сайлау округыннан читтә һәм тиешле сайлау округы чикләрендә булган шик белдерелгән һәм гаепләнүче затларны сак астында тоту урыннарындагы сайлаучыларның сайлаулар үткәргәндә тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирүе, «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон таләпләрен исәпкә алып, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә аның карары белән гамәлгә ашырыла.»;

18) 79 статьяга түбәндәге эчтәлекле 30$^{1}$ өлеш өстәргә:

«30$^{1}$. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә, әлеге Кодексның 76 статьясындагы 19 өлешендә һәм (яисә) 77 статьясындагы 19 өлешендә каралган тавыш бирүне һәм (яисә) әлеге Кодексның 76$^{1}$ статьясындагы 17 өлешендә каралган вакытыннан алда тавыш бирүне үткәргән очракта, тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссиясе беркетмәсен төзү (мондый тавыш бирү йомгаклары турындагы белешмәләрне формалаштыру) үзенчәлекләре Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.»;

19) 80 статьяга түбәндәге эчтәлекле 16 өлеш өстәргә:

«16. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә, әлеге Кодексның 76 статьясындагы 19 өлешендә һәм (яисә) 77 статьясындагы 19 өлешендә каралган тавыш бирүне һәм (яисә) әлеге Кодексның 76$^{1}$ статьясындагы 17 өлешендә каралган вакытыннан алда тавыш бирүне үткәргән очракта, югарырак комиссия тарафыннан, әлеге Кодексның 76 статьясындагы 19 өлешендә һәм (яисә) 77 статьясындагы 19 өлешендә каралган тавыш бирү һәм (яисә) әлеге Кодексның 76$^{1}$ статьясындагы 17 өлешендә каралган вакытыннан алда

тавыш бирү йомгаклары турында белешмәләрне исәпкә алып, җыелма таблица һәм тавыш бирү йомгаклары турында (сайлаулар нәтиҗәләре хакында) беркетмә төзү үзенчәлекләре Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.»;

20) 81 статьяның 1 өлешендә түбәндәге эчтәлекле яңа икенче җөмлә өстәргә: «Әлеге Кодексның 76 статьясындагы 19 өлешендә һәм (яисә) 77 статьясындагы 19 өлешендә каралган тавыш бирүне һәм (яисә) әлеге Кодексның $76^1$ статьясындагы 17 өлешендә каралган вакытыннан алда тавыш бирүне үткәргән очракта сайлаулар нәтиҗәләре турында беркетмәгә, җыелма таблицага мондый тавыш бирү белешмәләре кертелергә тиеш.»;

21) 89 статьяга түбәндәге эчтәлекле 8 өлеш өстәргә:

«8. Гражданнарның һәм юридик затларның ирекле иганәләренең минималь күләме тулаем Россия Федерациясе буенча җан башына яшәү минимумы күләменең 3 процентын тәшкил итә.»;

22) 101 статьяның 1 өлешендә «кандидатларның ышанычлы затларына, сәяси партияләргә,» сүзләрен төшереп калдырырга;

23) 102 статьяның 2 өлешендә «сентябрьнең икенче якшәмбесендә, ә чираттагы чакырылыш Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлауларны уздыру елында – шушы сайлауларда тавыш бирү көнендә» сүзләрен «әлеге Кодексның 6 статьясындагы 2 өлешендә каралган тавыш бирү көнендә» сүзләренә алмаштырырга, түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Бу чакта әлеге Кодексның 6 статьясындагы 2 өлешендә каралган тавыш бирү көненә кадәр биш ай алдан башлана һәм күрсәтелгән тавыш бирү көненнән соң бер ай узгач тәмамлана торган чорда мондый кабат сайлаулар күрсәтелгән тавыш бирү көненнән башка көнне уздырыла алмый һәм, әлеге Кодексның 6 статьясындагы 4 – 7 өлешләрендә каралган нигезләмәләрне исәпкә алып, күрсәтелгән көнгә билгеләнә.»;

24) 104 статьяның 2 өлешендә «сентябрьнең икенче якшәмбесенә, ә чираттагы чакырылыш Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлауларны уздыру елында – шушы сайлауларда тавыш бирү көненә» сүзләрен «әлеге Кодексның 6 статьясындагы 2 өлешендә каралган тавыш бирү көненә» сүзләренә алмаштырырга, түбәндәге эчтәлекле яңа өченче җөмлә өстәргә: «Бу чакта әлеге Кодексның 6 статьясындагы 2 өлешендә каралган тавыш бирү көненә кадәр биш ай алдан башлана һәм күрсәтелгән тавыш бирү көненнән соң бер ай узгач тәмамлана торган чорда мондый өстәмә сайлаулар күрсәтелгән тавыш бирү көненнән башка көнне уздырыла алмый һәм, әлеге Кодексның 6 статьясындагы 4 – 7 өлешләрендә каралган нигезләмәләрне исәпкә алып, күрсәтелгән көнгә билгеләнә.»;

25) $104^6$ статьяга түбәндәге эчтәлекле 6 өлеш өстәргә:

«6. Гражданнарның һәм юридик затларның ирекле иганәләренең минималь күләме тулаем Россия Федерациясе буенча җан башына яшәү минимумы күләменең 3 процентын тәшкил итә.»;

26) 104[14] статьяның 1 өлешендә «кандидатларның ышанычлы затларына,» сүзләрен төшереп калдырырга;

27) 104[16] статьяның 2 өлешендә «сентябрьнең икенче якшәмбесендә, ә чираттагы чакырылыш Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлауларны уздыру елында – шушы сайлауларда тавыш бирү көнендә» сүзләрен «әлеге Кодексның 6 статьясындагы 2 өлешендә каралган тавыш бирү көнендә» сүзләренә алмаштырырга, түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Бу чакта әлеге Кодексның 6 статьясындагы 2 өлешендә каралган тавыш бирү көненә кадәр биш ай алдан башлана һәм күрсәтелгән тавыш бирү көненнән соң бер ай узгач тәмамлана торган чорда мондый кабат сайлаулар күрсәтелгән тавыш бирү көненнән башка көнне уздырыла алмый һәм, әлеге Кодексның 6 статьясындагы 4 – 7 өлешләрендә каралган нигезләмәләрне исәпкә алып, күрсәтелгән көнгә билгеләнә.»;

28) 106 статьяга түбәндәге эчтәлекле 9 өлеш өстәргә:

«9. Гражданнарның һәм юридик затларның ирекле иганәләренең минималь күләме тулаем Россия Федерациясе буенча җан башына яшәү минимумы күләменең 3 процентын тәшкил итә.»;

29) 108 статьяда:

а) беренче абзацта «Җирле үзидарә органнарына» сүзләрен «1. Җирле үзидарә органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 2 өлеш өстәргә:

«2. Муниципаль берәмлек территориясендә берничә территория комиссиясе төзелгән булса, әлеге муниципаль берәмлектә җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләү һәм үткәрү вәкаләтләре Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары белән территория комиссияләренең берәрсенә йөкләнә.»;

30) 108[1] статьяның 5 өлешендәге икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль берәмлек территориясендә берничә территория комиссиясе төзелгән булса, округ комиссияләренең вәкаләтләре Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары белән күрсәтелгән территория комиссияләренә йөкләнергә мөмкин.»;

31) 121 статьяның 1 өлешендә «кандидатларның, сайлау берләшмәләренең ышанычлы затларына,» сүзләрен төшереп калдырырга;

32) 123 статьяның 2 өлешендә «сентябрьнең икенче якшәмбесенә, ә чираттагы чакырылыш Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы

депутатларын сайлауларны уздыру елында – шушы сайлауларда тавыш бирү көненә» сүзләрен «әлеге Кодексның 6 статьясындагы 2 өлешендә каралган тавыш бирү көненә» сүзләренә алмаштырырга, түбәндәге эчтәлекле яңа өченче җөмлә өстәргә: «Бу чакта әлеге Кодексның 6 статьясындагы 2 өлешендә каралган тавыш бирү көненә кадәр биш ай алдан башлана һәм күрсәтелгән тавыш бирү көненнән соң бер ай узгач тәмамлана торган чорда мондый өстәмә сайлаулар күрсәтелгән тавыш бирү көненнән башка көнне уздырыла алмый һәм, әлеге Кодексның 6 статьясындагы 4 – 7 өлешләрендә каралган нигезләмәләрне исәпкә алып, күрсәтелгән көнгә билгеләнә.»;

33) 128 статьяның 1 өлешендә «кандидатларның, сайлау берләшмәләренең ышанычлы затларына,» сүзләрен төшереп калдырырга;

34) 129 статьяның 2 өлешендә «сентябрьнең икенче якшәмбесендә, ә чираттагы чакырылыш Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлауларны уздыру елында – шушы сайлауларда тавыш бирү көнендә» сүзләрен «әлеге Кодексның 6 статьясындагы 2 өлешендә каралган тавыш бирү көнендә» сүзләренә алмаштырырга, түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Бу вакытта әлеге Кодексның 6 статьясындагы 2 өлешендә каралган тавыш бирү көненә кадәр биш ай алдан башлана һәм күрсәтелгән тавыш бирү көненнән соң бер ай узгач тәмамлана торган чорда мондый кабат сайлаулар күрсәтелгән тавыш бирү көненнән башка көнне уздырыла алмый һәм, әлеге Кодексның 6 статьясындагы 4 – 7 өлешләрендә каралган нигезләмәләрне исәпкә алып, күрсәтелгән көнгә билгеләнә.».

**2 статья**

«Татарстан Республикасы референдумы турында» 2003 елның 9 августындагы 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 8; 2005, № 3 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 44 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 10 статьяның 1 пунктында «Россия Федерациясе» сүзләре алдыннан «Әлеге Законның $15^1$ статьясындагы 7 һәм 10 пунктларында каралган очраклардан тыш,» сүзләрен өстәргә;

2) $15^1$ статьяда:
а) исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«$15^1$ статья. **Югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл, хәрби хәл режимы кертелгәндә референдум үткәрү**»;
б) түбәндәге эчтәлекле 4 – 10 пунктлар өстәргә:

«4. Федераль закон нигезендә, «Хәрби хәл турында» 2002 елның 30 гыйнварындагы 1-ФКЗ номерлы Федераль конституциячел закон нигезендә хәрби хәл кертелгәндә, Татарстан Республикасы Рәисе тавыш бирү көненә кадәр иң күбе 130 көн һәм кимендә 90 көн кала Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенә Татарстан Республикасы территориясендә референдум үткәрү турында тәкъдим җибәрергә хокуклы.

5. Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе әлеге статьяның 4 пунктында каралган тәкъдим кергән көннән алып биш көннән дә соңга калмыйча оборона өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру, норматив-хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органы һәм иминлек тәэмин итү өлкәсендә федераль башкарма хакимият органы белән консультацияләр үткәрә.

6. Федераль закон нигезендә әлеге статьяның 5 пунктында каралган консультацияләр нәтиҗәсе буенча һәм күрсәтелгән пунктта билгеләнгән срок эчендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе референдум билгеләү (үткәрү) турында яисә Татарстан Республикасы Рәисенең аны үткәрү хакындагы тәкъдимен кире кагу турында карар кабул итә.

7. Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе, әлеге статьяның 6 пунктында билгеләнгән срокларны истә тотып, Татарстан Республикасы территориясендә референдум билгеләү (үткәрү) турында карар кабул итә, бу хакта кичекмәстән Россия Федерациясе Президентына хәбәр итә. Бу чакта референдум тиешле дәрәҗәдәге комиссия тарафыннан оештырыла һәм үткәрелә.

8. Федераль закон нигезендә, әлеге статьяның 5 пунктында каралган консультацияләр нәтиҗәсе буенча Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе Татарстан Республикасы Рәисенең референдум үткәрү турындагы тәкъдимен кире каккан очракта, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе бу хакта кичекмәстән Татарстан Республикасы Рәисенә хәбәр итә.

9. Федераль закон нигезендә, әлеге статьяның 7 пункты нигезендә референдум билгеләнгәннән соң аны оештыру һәм үткәрү Россия Федерациясе гражданнарының гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч тудырса, референдумны үткәрү Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе карары белән кичектерелә, ул бу хакта кичекмәстән Россия Федерациясе Президентына хәбәр итә.

10. Федераль закон нигезендә, референдумны кичектереп тору өчен нигез булган хәлләр бетерелгән очракта, референдум кампаниясе Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе карары белән әлеге статьяның 4 – 7 пунктларында каралган тәртиптә яңадан башланырга мөмкин.»;

3) 16 статьяның 11 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Федераль закон, әлеге Закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр, шулай ук аларның вазыйфаи затлары комиссияләргә вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда ярдәм күрсәтергә тиеш, аерым алганда, түләүсез нигездә кирәкле биналар (биналарны территория һәм участок комиссияләренә биргәндә – биналардан файдалану чыгымнары һәм

коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү комиссияләр тарафыннан капланмый һәм түләнми), шул исәптән участок комиссияләренең референдум документларын (күрсәтелгән документларны архивка тапшырганчы йә законда билгеләнгән саклау вакытлары узып юкка чыгарганчы) һәм технологик җиһазларын саклау өчен, бирергә, бирелә торган биналарны һәм күрсәтелгән документларны һәм җиһазларны сак белән тәэмин итәргә, шулай ук түләүсез нигездә транспорт чаралары, элемтә чаралары, техник җиһазлар бирергә тиеш.»;

4) 17 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

«3. Әлеге Законның 50 статьясындагы 18 пунктында һәм (яисә) 51 статьясындагы 19 пунктында каралган тавыш бирүне тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан махсус участок комиссияләре төзелергә мөмкин. Мондый комиссияләр шул исәптән шик белдерелгән һәм гаепләнүче затларны сак астында тоту урыннары хезмәткәрләре арасыннан төзелергә мөмкин, йә мондый участок комиссияләренең вәкаләтләре башка участок комиссияләренә йөкләнә ала.»;

5) 22 статьяда:

а) $1^2$ пунктта «яисә түләүле граждан-хокукый шартнамәсе» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 14 пункт өстәргә:

«14. Фото һәм (яисә) видеога төшерү әлеге Закон нигезендә аны башкарырга хокукы булган затлар тарафыннан тавыш бирү сере бозылмаслык һәм референдумда катнашучыларның ихтыяр күрсәтүен контрольдә тоту мөмкинлеге булмаслык итеп, шулай ук референдумда катнашучылар исемлекләренә кертелгән һәм федераль законда билгеләнгән тәртиптә конфиденциаль мәгълүматка кертелгән мәгълүматы булган башка документлардагы персональ белешмәләрнең конфиденциальлеге сакланырлык итеп гамәлгә ашырылырга тиеш.»;

6) 26 статьяда:

а) $13^1$ пунктның икенче абзацында «таныклана» сүзеннән соң «, яисә мондый күчермә электрон рәвештә әзерләнергә мөмкин, бу очракта ул участок комиссиясе рәисенең, секретаренең электрон имзасы белән имзалана» сүзләрен өстәргә;

б) $15^1$ пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

в) түбәндәге эчтәлекле $15^2$ пункт өстәргә:

«$15^2$. Федераль закон нигезендә, әлеге Законның 50 статьясындагы 18 пунктында һәм (яисә) 51 статьясындагы 19 пунктында каралган тавыш бирүне үткәргән очракта, референдумда катнашучылар исемлекләре Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе билгеләгән тәртиптә төзелә.»;

7) 27 статьяның 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Шик белдерелгән һәм гаепләнүче затларны сак астында тоту урыннарында әлеге Законның 50 статьясындагы 18 пунктында һәм (яисә) 51 статьясындагы

19 пунктында каралган тавыш бирүне үткәрү өчен референдум участоклары Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан төзелергә мөмкин.»;

8) 47 статьяның 2 пунктында «башка урыннар булырга» сүзләреннән соң «, шулай ук Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе билгеләгән таләпләрне исәпкә алып, күзәтүчеләр һәм әлеге Законның 22 статьясындагы $1^2$ пунктында күрсәтелгән массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре өчен урыннар билгеләнергә» сүзләрен өстәргә;

9) 49 статьяда:

а) 9 пунктта «кимрәк була алмый» сүзләреннән соң «, моңа әлеге Законның $50^2$ статьясы нигезендә дистанцион рәвештә электрон тавыш бирүне үткәрү очрагы керми» сүзләрен өстәргә, түбәндәге эчтәлекле яңа өченче җөмлә өстәргә: «Бу очракта тапшырыла торган бюллетеньнәр саны, федераль законда башкасы билгеләнмәгән булса, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары белән билгеләнә.»;

б) түбәндәге эчтәлекле $12^1$ пункт өстәргә:

«$12^1$. Әлеге Законның 50 статьясындагы 18 пунктында һәм (яисә) 51 статьясындагы 19 пунктында каралган тавыш бирүне үткәргән очракта референдум документларын, бюллетеньнәрне дә кертеп, турыдан-туры участок комиссиясе тарафыннан әзерләү рөхсәт ителә, бу чакта әлеге статьяның 3 пункты нигезләмәләре кулланылмаска мөмкин. Референдум документларын әзерләү турында карар, бюллетеньнәрнең кирәкле тиражын һәм аларны әзерләү срокларын күрсәтеп, югарырак комиссия белән килештереп, участок комиссиясе тарафыннан кабул ителә.»;

10) 50 статьяда:

а) $2^1$ пунктта «референдум участокларында» сүзләреннән соң «, шулай ук әлеге статьяның 18 пунктында һәм (яисә) әлеге Законның 51 статьясындагы 19 пунктында каралган тавыш бирүне үткәрү өчен төзелгән референдум участокларында,» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле 18 пункт өстәргә:

«18. Референдум округыннан читтә һәм референдум округы чикләрендә булган шик белдерелгән һәм гаепләнүче затларны сак астында тоту урыннарындагы референдумда катнашучыларның референдум үткәргәндә тавыш бирүе, Федераль закон таләпләрен исәпкә алып, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә аның карары белән гамәлгә ашырыла.»;

11) 51 статьяда:

а) 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Федераль закон нигезендә күрсәтелгән реестр Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе билгеләгән тәртиптә электрон рәвештә төзелергә мөмкин.»;

б) түбәндәге эчтәлекле 19 пункт өстәргә:

«19. Референдум округыннан читтә һәм референдум округы чикләрендә булган шик белдерелгән һәм гаепләнүче затларны сак астында тоту урыннарындагы референдумда катнашучыларның референдум үткәргәндә тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирүе, Федераль закон таләпләрен исәпкә алып, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә аның карары белән гамәлгә ашырыла.»;

12) 53 статьяга түбәндәге эчтәлекле $29^1$ пункт өстәргә:

«$29^1$. Федераль закон нигезендә, әлеге Законның 50 статьясындагы 18 пунктында һәм (яисә) 51 статьясындагы 19 пунктында каралган тавыш бирүне үткәргән очракта, тавыш бирү йомгаклары турындагы участок комиссиясе беркетмәсен төзү (мондый тавыш бирү йомгаклары турындагы белешмәләрне формалаштыру) үзенчәлекләре Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.»;

13) 54 статьяга түбәндәге эчтәлекле 10 пункт өстәргә:

«10. Әлеге Законның 50 статьясындагы 18 пунктында һәм (яисә) 51 статьясындагы 19 пунктында каралган тавыш бирүне үткәргән очракта югарырак комиссия тарафыннан, әлеге Законның 50 статьясындагы 18 пунктында һәм (яисә) 51 статьясындагы 19 пунктында каралган тавыш бирү йомгаклары турында белешмәләрне исәпкә алып, тавыш бирү йомгаклары турында (референдум нәтиҗәләре хакында) җыелма таблица һәм беркетмә төзү үзенчәлекләре Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.»;

14) 55 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле тугызынчы абзац өстәргә:

«Әлеге Законның 50 статьясындагы 18 пунктында һәм (яисә) 51 статьясындагы 19 пунктында каралган тавыш бирүне үткәргән очракта референдум нәтиҗәләре турында беркетмәгә, җыелма таблицага мондый тавыш бирү белешмәләре кертелергә тиеш.».

**3 статья**

«Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (II өлеш); 2005, № 3 (I өлеш); 2008, № 5 (II өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8, № 12; 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 44 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $18^1$ статьяда:

а) исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18[1] статья. **Югары әзерлек һәм гадәттән тыш хәл, хәрби хәл режимы кертелгәндә референдум үткәрү**»;

б) түбәндәге эчтәлекле 4 – 10 пунктлар өстәргә:

«4. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә, «Хәрби хәл турында» 2002 елның 30 гыйнварындагы 1-ФКЗ номерлы Федераль конституциячел закон нигезендә хәрби хәл кертелгәндә, Татарстан Республикасы Рәисе тавыш бирү көненә кадәр иң күбе 130 көн һәм кимендә 90 көн кала Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенә референдум үткәрү турында тәкъдим җибәрергә хокуклы.

5. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе әлеге статьяның 4 пунктында каралган тәкъдим кергән көннән алып биш көннән дә соңга калмыйча оборона өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру, норматив-хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органы һәм иминлек тәэмин итү өлкәсендә федераль башкарма хакимият органы белән консультацияләр үткәрә.

6. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә әлеге статьяның 5 пунктында каралган консультацияләр нәтиҗәсе буенча һәм күрсәтелгән пунктта билгеләнгән срок эчендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе референдум билгеләү (үткәрү) турында яисә Татарстан Республикасы Рәисенең аны үткәрү хакындагы тәкъдимен кире кагу турында карар кабул итә.

7. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе, әлеге статьяның 6 пунктында билгеләнгән срокларны истә тотып, референдум билгеләү (үткәрү) турында карар кабул итә, бу хакта кичекмәстән Россия Федерациясе Президентына хәбәр итә. Бу чакта референдум тиешле дәрәҗәдәге комиссия тарафыннан оештырыла һәм үткәрелә.

8. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә, әлеге статьяның 5 пунктында каралган консультацияләр нәтиҗәсе буенча Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе Татарстан Республикасы Рәисенең референдум үткәрү турындагы тәкъдимен кире каккан очракта, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе бу хакта кичекмәстән Татарстан Республикасы Рәисенә хәбәр итә.

9. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә, әлеге статьяның 7 пункты нигезендә референдум билгеләнгәннән соң аны оештыру һәм үткәрү Россия Федерациясе гражданнарының гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч тудырса, референдумны үткәрү Россия Федерациясе Үзәк

сайлау комиссиясе карары белән кичектерелә, ул бу хакта кичекмәстән Россия Федерациясе Президентына хәбәр итә.

10. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә, референдумны кичектереп тору өчен нигез булган хәлләр бетерелгән очракта, референдум кампаниясе Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе карары белән әлеге статьяның 4 – 7 пунктларында каралган тәртиптә яңадан башланырга мөмкин.»;

2) 19 статьяда:

а) 11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон, әлеге Закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр, шулай ук аларның вазыйфаи затлары комиссияләргә вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда ярдәм күрсәтергә тиеш, аерым алганда, түләүсез нигездә кирәкле биналар (биналарны территория һәм участок комиссияләренә биргәндә – биналардан файдалану чыгымнары һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү комиссияләр тарафыннан капланмый һәм түләнми), шул исәптән участок комиссияләренең референдум документларын (күрсәтелгән документларны архивка тапшырганчы йә законда билгеләнгән саклау вакытлары узып юкка чыгарганчы) һәм технологик җиһазларын саклау өчен, бирергә, бирелә торган биналарны һәм күрсәтелгән документларны һәм җиһазларны сак белән тәэмин итәргә, шулай ук түләүсез нигездә транспорт чаралары, элемтә чаралары, техник җиһазлар бирергә тиеш.»;

б) түбәндәге эчтәлекле 16 – 18 пунктлар өстәргә:

«16. Казан шәһәре территориясендә референдум әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы комиссия вәкаләтләре Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе белән килештерелгән карары нигезендә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә йөкләнергә мөмкин.

17. Казан шәһәре территориясендә референдум әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы комиссия вәкаләтләрен үтәгән очракта, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әлеге Законның 20 статьясында каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

18. Әлеге Законның 52 статьясындагы 15 пунктында һәм (яисә) 53 статьясындагы 19 пунктында каралган тавыш бирүне һәм (яисә) әлеге Законның $52^1$ статьясындагы 17 пунктында каралган вакытыннан алда тавыш бирүне тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан махсус участок комиссияләре төзелергә мөмкин. Мондый комиссияләр шул исәптән шик белдерелгән һәм гаепләнүче затларны сак астында тоту урыннары хезмәткәрләре арасыннан төзелергә мөмкин, йә мондый участок комиссияләренең вәкаләтләре башка участок комиссияләренә йөкләнә ала.»;

3) 20 статьяда:

а) беренче абзацта «Референдум» сүзен «1. Референдум» сүзенә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 2 пункт өстәргә:

«2. Муниципаль берәмлек территориясендә берничә территория комиссиясе төзелгән булса, бу муниципаль берәмлектә референдумны әзерләү һәм үткәрү вәкаләтләре Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары белән территория комиссиясенең берәрсенә йөкләнә.»;

4) 24 статьяда:

а) $1^2$ пунктта «яисә түләүле граждан-хокукый шартнамә» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 14 пункт өстәргә:

«14. Фото һәм (яисә) видеога төшерү әлеге Закон нигезендә аны башкарырга хокукы булган затлар тарафыннан тавыш бирү сере бозылмаслык һәм референдумда катнашучыларның ихтыяр күрсәтүен контрольдә тоту мөмкинлеге булмаслык итеп, шулай ук референдумда катнашучылар исемлекләренә кертелгән һәм федераль законда билгеләнгән тәртиптә конфиденциаль мәгълүматка кертелгән мәгълүматы булган башка документлардагы персональ белешмәләрнең конфиденциальлеге сакланырлык итеп гамәлгә ашырылырга тиеш.»;

5) 25 статьяның 4 пунктына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Әлеге Законның 19 статьясындагы 18 пункты нигезендә төзелгән участок комиссиясе рәисе вазыйфага комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары арасыннан билгеләп куела һәм вазыйфадан Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары белән азат ителә.»;

6) 27 статьяда:

а) $14^1$ пунктның икенче абзацында «таныклана» сүзеннән соң «, яисә мондый күчермә электрон рәвештә әзерләнергә мөмкин, бу очракта ул участок комиссиясе рәисенең, секретареның электрон имзалары белән имзалана» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле $16^1$ пункт өстәргә:

«$16^1$. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә, әлеге Законның 52 статьясындагы 15 пунктында һәм (яисә) 53 статьясындагы 19 пунктында каралган тавыш бирүне һәм (яисә) әлеге Законның $52^1$ статьясындагы 17 пунктында каралган вакытыннан алда тавыш бирүне үткәргән очракта, референдумда катнашучылар исемлекләре Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе билгеләгән тәртиптә төзелә.»;

7) 28 статьяның 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Шик белдерелгән һәм гаепләнүче затларны сак астында тоту урыннарында әлеге Законның 52 статьясындагы 15 пунктында һәм (яисә) 53 статьясындагы

19 пунктында каралган тавыш бирүне һәм (яисә) әлеге Законның $52^1$ статьясындагы 17 пунктында каралган вакытыннан алда тавыш бирүне үткәрү өчен референдум участоклары Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан төзелергә мөмкин.»;

8) 49 статьяның 2 пунктында «башка урыннар булырга» сүзләреннән соң «, шулай ук Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе билгеләгән таләпләрне исәпкә алып, күзәтүчеләр һәм әлеге Законның 24 статьясындагы $1^2$ пунктында күрсәтелгән массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре өчен урыннар билгеләнергә» сүзләрен өстәргә;

9) 51 статьяда:

а) 8 пунктта «кимрәк була алмый» сүзләреннән соң «, моңа әлеге Законның $52^2$ статьясы нигезендә дистанцион рәвештә электрон тавыш бирүне үткәрү очрагы керми» сүзләрен өстәргә, түбәндәге эчтәлекле яңа бишенче җөмлә өстәргә: «Бу очракта тапшырыла торган бюллетеньнәр саны, федераль законда башкасы билгеләнмәгән булса, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары белән билгеләнә.»;

б) түбәндәге эчтәлекле $11^1$ пункт өстәргә:

«$11^1$. Әлеге Законның 52 статьясындагы 15 пунктында һәм (яисә) 53 статьясындагы 19 пунктында каралган тавыш бирүне һәм (яисә) әлеге Законның $52^1$ статьясындагы 17 пунктында каралган вакытыннан алда тавыш бирүне үткәргән очракта референдум документларын, бюллетеньнәрне дә кертеп, турыдан-туры участок комиссиясе тарафыннан әзерләү рөхсәт ителә, бу чакта әлеге статьяның 3 пункты нигезләмәләре кулланылмаска мөмкин. Референдум документларын әзерләү турында карар, бюллетеньнәрнең кирәкле тиражын һәм аларны әзерләү срокларын күрсәтеп, югарырак комиссия белән килештереп, участок комиссиясе тарафыннан кабул ителә.»;

10) 52 статьяда:

а) $2^1$ пунктта «референдум участокларында» сүзләреннән соң «, шулай ук әлеге статьяның 15 пунктында һәм (яисә) әлеге Законның 53 статьясындагы 19 пунктында каралган тавыш бирүне һәм (яисә) әлеге Законның $52^1$ статьясындагы 17 пунктында каралган вакытыннан алда тавыш бирүне үткәрү өчен төзелгән референдум участокларында,» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле 15 пункт өстәргә:

«15. Референдум округыннан читтә һәм референдум округы чикләрендә булган шик белдерелгән һәм гаепләнүче затларны сак астында тоту урыннарындагы референдумда катнашучыларның референдум үткәргәндә тавыш бирүе, «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон таләпләрен исәпкә алып, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә аның карары белән гамәлгә ашырыла.»;

11) $52^1$ статьяга түбәндәге эчтәлекле 17 пункт өстәргә:

«17. Референдум округыннан читтә һәм референдум округы чикләрендә булган шик белдерелгән һәм гаепләнүче затларны сак астында тоту урыннарындагы референдумда катнашучыларның референдум үткәргәндә вакытыннан алда тавыш бирүе, «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм аларның референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон таләпләрен исәпкә алып, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда гамәлгә ашырыла.»;

12) 53 статьяда:

а) 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Күрсәтелгән реестр «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе билгеләгән тәртиптә электрон рәвештә төзелергә мөмкин.»;

б) түбәндәге эчтәлекле 19 пункт өстәргә:

«19. Референдум округыннан читтә һәм референдум округы чикләрендә булган шик белдерелгән һәм гаепләнүче затларны сак астында тоту урыннарындагы референдумда катнашучыларның референдум үткәргәндә тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирүе, «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон таләпләрен исәпкә алып, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә аның карары белән гамәлгә ашырыла.»;

13) 55 статьяга түбәндәге эчтәлекле $29^1$ пункт өстәргә:

«$29^1$. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә, әлеге Законның 52 статьясындагы 15 пунктында һәм (яисә) 53 статьясындагы 19 пунктында каралган тавыш бирүне һәм (яисә) әлеге Законның $52^1$ статьясындагы 17 пунктында каралган вакытыннан алда тавыш бирүне үткәргән очракта, тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссиясе беркетмәсен төзү (мондый тавыш бирү йомгаклары турындагы белешмәләрне формалаштыру) үзенчәлекләре Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.»;

14) 56 статьяның 6 пунктына түбәндәге эчтәлекле алтынчы абзац өстәргә:

«Әлеге Законның 52 статьясындагы 15 пунктында һәм (яисә) 53 статьясындагы 19 пунктында каралган тавыш бирүне һәм (яисә) әлеге Законның $52^1$ статьясындагы 17 пунктында каралган вакытыннан алда тавыш бирүне үткәргән очракта референдум нәтиҗәләре турында беркетмәгә, җыелма таблицага мондый тавыш бирү белешмәләре кертелергә тиеш.».

**4 статья**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 21 статьясындагы 5 өлешенең алтынчы абзацына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 5, № 6 (I өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 17 (I өлеш), № 24 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), «ул төзелгән көннән соң бер елдан да соңга калмыйча уздырылырга тиеш» сүзләрен «сайлаулар һәм референдумнар турындагы законнарда каралган срокларда уздырыла» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**5 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 29 сентябрь
№ 90-ТРЗ